Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы 18 нче “Карлыгач”
катнаш балалар бакчасы
муниципаль мәктәпкәчә белем һәм тәрбия бирү бюджет учреждениясе

# Театр яктылыкка, нурга илтә,
# Кире юлга җибәрми, үнга илтә.

Гыйльметдинова Миләүшә Рәшит кызы,
югары квалификацион категорияле
татар теле тәрбиячесе

## Аңлатма язуы

Күренекле мәгърифәтче Каюм Насыйри: **"Табигый сәләтлелек ул очкын гына, ул сүнәргә дә, кабынып китәргә дә мөмкин, аның кабынып китеп, зур ялкынга әверелүендә төп мәҗбүри көч булып хезмәт һәм үз-үзеңә таләпчән булу тора,"** – дигән.

Балаларны татар теленә өйрәтүдә театр уйнау зур урын алып тора. Театрда катнашу балаларның күпьяклы талантларын ача. Балаларның сөйләм теле камилләшә, баей. Ә экиятләрне уйнау баланың төрле яктан үсешен белем өлкәләре интеграциясе аша тормышка ашыра. Аларның сөйләм теле үсә, дикцияләре, интонация белән уйнарга өйрәнәләр. Балалар курчаклар, өстәл, ком, күләгә, конуслы уенчыклар, маскалар һәм башка бик күп төрле театрлар белән танышалар, алар белән уйнарга өйрәнәләр. Әкиятләр сәхнәләштерү балаларда нәфис сәнгатькә кызыксыну уята, бу өлкәдә талантларын ачарга ярдәм итә. Балаларда әйләнә – тирәдәге матурлыкка кызыксыну уята. Матур итеп бизәлгән күп функцияле пәрдә, экият геройларын билгеләүче матур костюмнар, экиятне уйнау өчен әзерләнгән декорациянең яхшы дәрәҗәдә ясалган булуы бик мөһим. Балаларның әти – әниләре белән берлектә чыгышларга, бәйгеләргә, экиятләрне сәхнәләштерүгә бергәләп катнашуы да зур тәрбияви мәгънәгә ия, аларның эстетик яктан формалашуына зур йогынты ясый.

Театр аркылы балаларны татар теленә өйрәтәбез, татар халкының күренекле язучыларының әсәрләре белән таныштырабыз.

# Кишер



***Зурлар төркеме өчен***

*Балалар  музыка астында залга үтәләр һәм һәрберсе үз урынына утыра. Бабай итеккә олтан сала, әби оекбаш бәйли, әти гәҗит укый, әни камыр куя, малай белән кыз уйнап утыралар, песи бабай , эт өй янында утыра, ә тычкан өй артында. Башка балалар өй кырына тезелеп басалар.*

**Тәрбияче:** Сезнең игътибарыгызга «Кишер» экиятен тәкъдим итәбез.

**1 өлеш.**

**Җыр  «Минем өем»**
**Балалар:** Бу өй матур,
Бу өй зур.
**Балалар:** Монда яши бабай
**Бабай:** Мин бабай.
**Балалар:** Монда яши әби.
**Әби:** Мин әби.
**Балалар:** Монда яши әби.
**Әти:** Мин әти.
**Балалар:** Монда яши әни.
**Әни:** Мин әни.
Монда яши малай.
**Малай:** Мин малай.
**Балалар:** Монда яши кыз.
**Кыз:** Мин кыз.
**Бергә:** Әйе шул, әйе шул,
Бу өй матур.
Бу өй зур.

**2 өлеш.**
**Тәрбияче:** Борын – борын заманда бер авылда шундый хәл була. Давным – давно в одной деревне случилась это история. Бабай кишер утырта. Дед посадил морковь.

*Көй яңгырый. Бабай чыга. Кулында лейка һәм көрәк. Бабай кишер чәчә. Су сибә. Һәм кире кереп китә.*




*Кишер чыга һәм утыра. Балалар бер-бер артлы чыгып кишерне мактыйлар.*

**1 бала:** Кечкенә кишер.

**Кишер:** Әйе, әйе кечкенә кишер

**2 бала:** Тәмле кишер.

**Кишер:** Әйе, әйе тәмле кишер.

**3 бала:** Баллы кишер.

**Кишер:** Әйе, әйе баллы кишер.

**4 бала:** Матур кишер.

**Кишер:** Әйе, әйе матур кишер.

**5 бала:** Зур кишер.

**Кишер:** Әйе, әйе зур кишер.



*Балалар түгәрәккә басалар һәм “Кишер” җырын җырлыйлар.*

Кишер, кишер
Тәмле кишер,
Зур кишер,
Баллы кишер.

Кушымта *(Кишер җырлый)*
Әйе, әйе
Мин кишер.
Зур кишер,
Баллы кишер.

Кишер, кишер
Матур кишер,
Зур кишер,
Баллы кишер.

Кушымта *(Кишер җырлый)*
Әйе, әйе

Мин кишер.
Зур кишер,
Баллы кишер.

*Җырны башкарганнан соң, балалар яшелчә битлекләре кияләр һәм түтәлләр ясап идәнгә утыралар.*

**Зөлеш.**

*Бабай чыга.Кишерне күреп шакката, соклана.*

**Бабай:** Ой, ой, ой! Зур кишер!

*Бабай кишерне тарта.*

**Бабай:** 1, 2, 3, 4, 5. Юк. Әби, кил монда.

**Бергә тарталар:** 1, 2, 3, 4, 5.

**Әби:** Юк. Азат, кил монда.

**Бергә тарталар:** 1, 2, 3, 4, 5.

**Азат:** Юк. Алсу, кил монда**.**

**Бергә тарталар:** 1, 2, 3, 4, 5.

**Азат:** Юк.әти, кил монда.

**Бергә тарталар:** 1, 2, 3, 4, 5.

**Алсу:** Юк.әни, кил монда.

**Бергә тарталар:** 1, 2, 3, 4, 5.

**Әти:** Юк булмый. Акбай, кил монда.

**Бергә тарталар:** 1, 2, 3, 4, 5.

**Әни:** Юк булмый. Песи, кил монда.

**Бергә тарталар:** 1, 2, 3, 4, 5.

*Тартып чыгаралар.*

**Бергә:** О-о-о! Зур!



**4 өлеш.**

*Әби чыгып китә.*

**Җыр “Бар матур бакча”.**

Бар матур бакча,
Анда кишер үсә.
Менә шундый кишер зур,
Менә шундый кечкенә.
*Кушымта*
Кишер, кишер кил әле
Биеп биеп кит әле
Әллә-лә,әллә-лә,
Биеп, биеп кит әле.
2) Бар матур бакча,
Анда суган үсә.
Менә шундый суган зур,
Менә шундый кечкенә.
*Кушымта:*
Суган, суган, кил әле,
Биеп, биеп кит әле.
Әллә-лә, әллә-лә,
Биеп, биеп кит әле
3) Бар матур бакча,

Анда кыяр үсә.
Менә шундый кыяр зур,
Менә шундый кечкенә
*Кушымта:*
Кыяр, кыяр, кил әле
Биеп, биеп кит әле.
Әллә-лә, әллә-лә,
Биеп, биеп кит әле.

**5 өлеш.**

*Балалар ярым түгәрәк ясап басалар.*

**Бабай:** Әби кая? Әби кил монда.

Кулына бәлеш тотып әби чыга, балаларны чәй эчәргә чакыра.

**Әби:** Сез уйнаганда тәмле бәлеш пешердем. Сезне чәй эчәргә чакырам.

